СОВЕТ
СТАРОШАЙМУРЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ШӘЙМОРЗА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**№ 4/4** **«17» декабрь 2020 ел**

Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль пенсиягә
чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата
бүләкне түләү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 февралендәге 46/1 номерлы карарына, коррупциягә каршы экспертиза нигезендә, Чүпрәле районы прокурорының 2020 елның 16 декабрендәге 02-01-16/2020 номерлы таләпләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советының «Даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга акчалата бүләкләүләр, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 24 апрелендәге 32/1 номерлы карары белән расланган 12 кушымта «Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү тәртибе һәм шартлары» тәртибенең 1 пунктына (2018 елның 23 маендагы 33/1 номерлы 2018 елның 11 сентябрендәге 37/2 номерлы; 2018 елның 14 ноябрендәге 36/2 номерлы; 13.11.2020 ел, № 3/4 редакциясендә) - «муниципаль вазыйфа биләүче затның эш стажын билгеләү өчен законнар нигезендә кирәкле башка документлар.» сүзләрен төшереп калдырып үзгәрешләр кертергә.

2.Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлегенең рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Иске Шәйморза авыл җирлеге башлыгы: И.Д.Мөхитова